КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 апрель г.Казань № 426

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2008 ел, 10 ноябрь, 799 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2008 ел, 10 ноябрь, 799 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 октябрь, 804 нче, 2012 ел, 21 июнь, 538 нче, 2014 ел, 1 февраль, 56 нчы, 2014 ел, 29 апрель, 278 нче, 2015 ел, 18 апрель, 266 нчы, 2016 ел, 21 июнь, 417 нче, 2017 ел, 2 июнь, 333 нче, 2019 ел, 8 май, 385 нче, 2020 ел, 13 ноябрь, 1021 нче, 2022 ел, 7 май, 425 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм дәүләт хакимиятенең башка федераль органнарының карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары карарлары һәм боерыклары, социаль партнерлыкның федераль, төбәкара, төбәк, тармак (тармакара) һәмтерриториаль дәрәҗәләрендә хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр арасында төзелгән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга сала торган килешүләр, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.»;

әлеге карар белән расланган Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 10 ноябрь, 779 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 апрель, 426 нчы
карары редакциясендә)

Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы, комиссия секретаре |
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Вәлиуллов Рөстәм Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары |
| Галәвов Рөстәм Әсфан улы | Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторы (килешү буенча) |
| Германов Антон Анатольевич | «Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең хезмәтне саклау хезмәте җитәкчесен (килешү буенча) |
| Гыймаев Илшат Сәхап улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Залаков Наил Ринат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |
| Запаров Марат Миңнебай улы | «АНКОР» инженерлык бюросы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең хезмәтне саклау һәм сәнәгать иминлеге буенча баш инженеры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипов Марс Миңнехан улы | Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте Идел буе идарәсенең дәүләт энергетика күзәтчелеге һәм гидротехник корылмаларга күзәтчелек төбәкара бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Краснова Ольга Михайловна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кузьмичева Елена Ивановна | Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе (килешү буенча) |
| Курзенева Алла Геннадьевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе бүлеге башлыгын |
| Нигъмәтҗанова Энҗе Нияз кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Пилина Айсылу Әхмәтхан кызы | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Прокофьева Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабурская Алина Викторовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенең дәүләт гарантияләре, социаль ярдәм, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча бүлек башлыгы |
| Степаненко Игорь Юрьевич | «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең Сәнәгать иминлеге һәм экология департаменты директоры (килешү буенча) |
| Урманов Даян Ренат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе |
| Фәйзетдинова Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе |

| | |
|---|---|
| Фатыйхов Илдар Рәзин улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шәрәфетдинов Рәис Мифтах улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесе. |

_________________________________